ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ГРАЖДАННАРЫНЫҢ УТЫЗ ДҮРТНЧЕ ҖЫЕНЫ

КАРАР №5

2018 елның 19 декабре Иннополис ш.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2018 - 2035 елларга коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасын раслау турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2013 елның 14 июнендәге 502 номерлы карары, Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрнең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларын эшләү турында» 2011 елның 06 маендагы 204 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Иннополис шәһәре Мэрының мәгълүматны тыңлаганнан соң,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 - 2035 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) мәгълүмат сайтында, шулай ук Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Рәислек итүче,
Иннополис шәһәре Мэры Р.Р.Шагалеев